
# Халыклар туганлыгы

15 декабрь көнне Сара Садыйкова исемендәге Концертлар залында милли җәмгыятьләрнең «Халыклар туганлыгы – зур байлык» дип исемләнгән юбилей фестивале узды.

Чаллы шәһәре башлыгы урынбасары Хәйдәр Галәветдинов әлеге тантанада катнашучыларны бәйрәм белән котлап: «Менә 15нче тапкыр шәһәребездә яшәүче төрле милләт вәкилләрен бергә туплаучы бу фестиваль – халыклар арасындагы дуслыкка мәдхия җырлау, туганлык хисе белән сугарылган милли сәнгатьнең рухын саклаучыларны хөрмәтләү чарасы. Күпләребез илнең төрле почмакларыннан килеп, шушында төпләнеп калган кешеләр. Шушы җирлекнең тарихи фундаментында гигант КамАЗ заводлары, гүзәл калабыз Чаллы белән бергә, иң зур байлыгыбыз – какшамас дуслыкны төзедек. Дистәләгән еллар буе бер зур гаилә булып яшибез һәм аны бернинди сынаулар да җимерә алмас», – диде.

Әйе, шәһәребездә оешкан 19 милли җәмгыятьнең телләре, сәнгатьләре, диннәре һәм йолалары төрле булуга да карамастан, иңне-иңгә куеп, үзара тату яшәве, бер-берсен якын итүләре, хөрмәте – моңа зур дәлил. Фестиваль әлеге җәмгыятьләрдә эшләп килүче иҗат коллективларының чыгышы, һәр халыкның яшәү рәвеше, милли рухы белән сугарылган иде. Керәшеннәрнең Питрау, Нардуган бәйрәмнәрен, Кыз бирү йолаларын күрсәтеп башкарган җырлы-биюле чыгышы залдагыларның берсен дә битараф калдырмады. «Карендәшләр» фольклор ансамбле милли колоритны һәркем күңеленә үтәрлек итеп башкаруы белән сокландырса, танылган җырчыбыз В.Агапов һәм ул җитәкләгән «Моңлы Чаллы» җырчылары керәшен көйләренең бөтен матурлыгын тамашачыга тагын бер кат ачып бирде. Шулай ук чуаш, удмурт, башкорт халыкларының моңлы җырлары, кайнар йөрәкле Кавказ егетләренең ялкынлы биюләре һәм башка халыкларның чыгышлары тамашачы күңелендә кабатланмас тойгылар, дулкынлану катыш соклану хисләре уятты.




**Г.ЕГОРОВА.**